**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350,Апас штп. , Совет урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 163 ... 12.05.2020

**Тәрбияләнүчеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрология тибындагы интернат-йортларга җибәрү турында карарлар бирү буенча муниципаль берәмлекләр тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында**

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" гы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты **к а р а р б и р ә :**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 1 апрелендәге 104 номерлы карары белән расланган, картлар һәм инвалидлар өчен интернат-йортларга стационар хезмәт күрсәтүгә җибәрү турында карарлар бирү буенча муниципаль берәмлекләр тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктының 5 пунктчасын төшереп калдырырга;

2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«инвалидлык турында Федераль реестрдагы белешмәләр. Федераль инвалидлар реестрында тиешле мәгълүматлар булмаган очракта, хезмәт күрсәтү турында карар мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә кабул ителә.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карар 2020 елның 1 июленнән үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л. Р. Сафинга йөкләргә.

**Җитәкче** **А. А. Тугушев**